УДК 908

# РИЗАЭДДИН ФӘХРЕДДИННЕҢ *«ШУРА»* ЖУРНАЛЫНДАГЫ ДИНИ ҺӘМ МИЛЛИ КИЕМ БЕЛӘН БӘЙЛЕ МӘКАЛӘЛӘРЕ

***И.Г. Мифтахов***

*Әнкара университеты*
*Әнкара, Төркия*
*dajbog12@gmail.com*

Мәкаләдә танылган галим, дин әһеле, әдип һәм журналист Ризаэддин Фәхреддиннең үзе баш мөхәррир булып хезмәт иткән *«Шура»* журналында басылып чыккан *«Киемнәр хакында»* исемле мәкаләләре анализлана. Ризаэддин Фәхреддин бу язмаларында кием-салымны дини, милли, икътисадый, медицина һәм зәвык җәһәтләреннән тирән анализлый. Мөселманнар өчен махсус киемнең булуы яки булмавы, башка милләт һәм дин кешеләренең киемнәрен мөселманнарга киюнең рөхсәт ителүе кебек мәсьәләләр карала. Кием-салымның исламият күзлегеннән караганда бер изге тарафы булмавы аңлатыла. Киемнең кешенең холкына, үз-үзен тотышына тәэсире булуы билдерелә. Фәхреддин үзенең мәкаләләрендә дин әһелләре өчен ислам тарафыннан билгеләнгән махсус форма булмавын, һәр халыкның климат шартларына, гореф-гадәтләренә күрә кием формалары булуын ачыклый. Галимнәрнең һәм дин әһелләренең башкалардан кием белән түгел, ә гыйлем, өстен әхлак белән аерылып торулары кирәклеген искәртә. Ләкин шуңа карамастан дин әһелләре өчен ул җирлектә кабул ителгән кием, ягъни татарларда чапан белән чалма киюләре күркәм бер гамәл булуын белдерә. Ризаэддин Фәхреддин милли киемгә карата җитди позициядә тора, милли кием куллану, аны саклау кирәклегенә басым ясый. Милли киемне саклауда төп вазыйфа имамнар яки газета һәм журналларда язмалар белән генә саклау мөмкин түгел. Төп хезмәт милли кием җитештерүче һәм шулар белән сату итүче сәүдәгәрләр өстендә булуын белдерә. Ризаэддин Фәхреддиннең кием-салым белән бәйле бу язмалары XX гасыр башындагы җәдитчеләрнең киемгә булган карашларын өйрәнү өчен мөһим бер чыганак булып тора.

**Төп төшенчәләр:** Ризаэддин Фәхреддин, татарлар, *«Шура»* журналы, дини форма, милли кием, XX гасыр башы, ислам, җәдитчелек

**Сылтама ясау өчен:** Мифтахов И.Г. Ризаэддин Фәхреддиннең *«Шура»* журналындагы дини һәм милли кием белән бәйле мәкаләләре // Историческая этнология. 2020. Т. 5, № 2. С. 254–268. https://doi.org/10.22378/he.2020-5-2.254-268

*... Иманлы түгел киемеңез, иманлыдыр калебеңез*
*Иман түгел киемдә, бәлки иман калебтә...*
*(Чапан илә пальто гаугасы исемле әсәрдән)*

XX гасыр башы татар халкы җәмгыять тормышының иң хәрәкәтле чорларыннан берсе булып тора. XIX гасырның икенче яртысында башланып киткән җәдитчелек хәрәкәте яңа гасыр башында үзенең алтын чорын яши. Әлеге чор җәдитчеләр белән кадимчеләр арасында көрәшнең дә иң кызган вакыты. XX гасыр башында яңа гына мәйданга чыккан вакытлы татар матбугаты да моңа үз өлешен кертә. Россия империясендә татарларга газета һәм журналлар нәшер итәргә рөхсәт иткәнче, кадимчеләр белән җәдитчеләр рисаләләр, китаплар аркылы бер-берсе белән фәнни көрәш алып барганнар, бер-берләренә каршы рәддияләр язганнар. Вакытлы матбугат барлыкка килгәч исә бу җиңелрәк хәл ителгән. Чөнки газета яки журналлар даими рәвештә чыгып тора һәм күп халык арасында тарала. Рисаләләр исә халыкның бөтен катлавына ирешмәү сәбәпле вакытлы матбугат кадәр тәэсир итә алмый.

Ул чорда җәдитчеләр белән кадимчеләр арасында кызу бәхәсләрнең берсе булып кием-салым бәхәсе тора.

Мисал өчен, 1910 елда Казанда басылган *«Бетсен чапан күтәрелсен йөздән пәрдәләр»* исемле «Ачык йөз» тәхәллүсе белән язылган әсәрдә татар хатыннарының сарт[1] чапаны киеп йөрүләре тәнкыйть ителә, чапан урынына калфак тагып, шәл бөркәнергә өндәлә (Ачык йөз 1910: 5, 7).

1900 елларда язылып, 1906 елда басылган *«Чапан илә пальто гаугасы»* исемле кечкенә генә шигъри әсәрдә дә шулай ук кием мәсьәләсенә басым ясала. Автор ике тарафның да чиктән ашуларын белдерә һәм икесенең дә урта юлдан барулары кирәклегенә ишарәт итә (Сахибе 1906: 3–4). Шулай ук монда бары тик тышкы кием, кыяфәт белән генә тәрәккый тарафдары булу мөмкин булмавын белдереп болай диелә:

Яңаларда шул эш бар, пәлтә кыска брюка тар
Бу эшне дә тәрәккый дип йөрүче кешеләр бар
Яңалык тәрәккыйлек түгел ул пәлтә кимәк
Бәлки будыр яңалык, мәгарифне күп итмәк (Сахибе 1906: 5).

Кадимче тарафның мәшһүр шәхесләреннән Морат Рәмзи дә җәдитче яшьләрне тәнкыйтьләп язган бер шигырендә болай дип әйтә:

«Өйлә[2] малайлар ки, дин вә диянәттән бихәбәр
Башларына шапка киеп, билләренә каеш баглайлар

[1] Сарт дип ул чорда Урта Азиядә утрак тормышта яшәүче халыкларны атап йөрткәннәр, аларның күпчелек өлешен үзбәкләр тәшкил иткән

[2] Өйлә – шундый

Өйлә малайлар ки, кяффә-и мәгарифтән[3] бихәбәр» дип яза (Рәмзи 1911: 105).

Ягъни аларның дини гыйлемнәре булмавына басым ясый һәм билләренә каеш тагып, эшләпә киюләрен тәнкыйть итә.

Әлбәттә, һәр милләтнең киенү рәвеше, кием-салымы заман белән бергә үзгәрә бара. Кайсыбер яңа формалар өстәлә, кайсыберләре югала тора[4]. Моның табигый бер нәрсә булуын Ризаэддин Фәхреддин дә кабул итә.

Кием-салым кеше тормышында мөһим урын алып тора. Ул кешенең ия булган мәдәниятның аның карашларына ишарәт итүе мәгълүм бер нәрсә. Шулай ук тышкы кыяфәт аша аның җенесе, дәрәҗәсе, яшәгән төбәге, милләте, мәдәнияте хәтта хис-тойгыларын да белдерергә сәләтле (Yüksel Uysal 2016: 307).

***Ризаэддин Фәхреддиннең «Шура» журналындагы кием белән бәйле язмалары.*** Кием-салым белән бәйле буларак *«Шура»* журналы идарәсенә 1910 елда Исхак Таҗетдинов тарафыннан мөселманнар өчен кию һәм файдалану тыелган киемнәр турында сорау бирелә. Ләкин бу сорауга идарә ул вакытта бик кыска итеп мөселманнар өчен кияргә һәм кулланырга рөхсәт ителгән кием-салым фикыһ һәм хәдис китапларында бәян ителгән дип җавап бирү белән чикләнә (Таҗетдинов 1910: 62). Кием-салым белән бәйле тәфсилле язмалар исә бу сораудан соң биш ел үткәч каләмгә алына.

Ризаэддин Фәхреддиннең милли һәм дини кием белән бәйле мәкаләләре *«Шура»* журналының 1915 елгы 8, 9, 10 нчы саннарында басылып чыга. Аның үзенең дә белдерүенчә, бу чорда инде кием низаглары бераз сүрелә төшкән. Ике тарафта булучылар да бу вәзгыятькә күпмедер дәрәҗәдә ияләшкәннәр. Ләкин әле бу көнүзәк мәсьәлә булудан туктамаган. Шуңа күрә Фәхреддин дини, милли кием мәсьәләсендә үз фикерләрен каләмгә ала. Ул шулай ук 1917 елда басылган *«Җәвамигел-Кәлим шәрехе»* исемле китабында да хәдисләргә шәрех язганда кием темасына киң урын бирә[5].

*«Шура»* журналында *«Киемнәр хакында»* дип аталган беренче язмасында Фәхреддин үз гасырында ислам дөньясында дин исеменнән иң күп шау-шу тудырган мәсьәләнең кием мәсьәләсе булуын белдерә. Шуның белән бергә бу проблеманы электән үк булуын, мәҗүси баш киеме кигән кешенең кяфер булу яки булмавы фәтва китапларында язылуы, ләкин борынгы дәвердә моның белән бары тик галимнәр генә мәшгуль булуын, хәзерге чорда исә бөтен кешене кызыксындырган гомуми бер мәсьәләгә әйләнүен аңлата. Шуңа күрә кием мәсьәләсе инде хәл ителеп, әлеге

[3] *Кяффә-и мәгарифтән - бөтен мәгарифтән.*

[4] Бу хакта киңрәк мәгълүмат өчен карагыз: (Воробьев 1930: 464).

[5] Әлеге китапта кием-салым белән бәйле 30, 57, 62, 86, 128, 167, 192, 299 номерлы хәдисләр һәм ул хәдисләргә шәрехләр бирелә.

сорауга нокта куелырга тиешлеген искәртә. Ризаэддин Фәхреддиннең әлеге язмасы басылганнан соң 105 ел үтеп киткән, ләкин әлеге мәсьәләгә һаман нокта куелганы юк дип әйтергә мөмкин. Мөселман кием-салымы белән бәйле бәхәсләр, аңа төрле карашлар әле бүгенге көндә дә дәвам итеп килә.

**Төркиләрнең борынгы киемнәре һәм кием-салымның үзгәрүе.** Ризаэддин Фәхреддин үзенең мәкаләсен төркиләрнең борынгы киемнәренә бер күзәтү ясау белән башлап җибәрә. Ул төркиләрнең, Идел буе болгарларының киемнәрен тасвирлаган чыганакларның бик аз булуын ассызыклап үтә. Монда Ибн Фазлан белән Ибн Батутаның хезмәтләре генә искә алына. Ибн Фазланның сәяхәтнамәсендә болгарларның киемнәре турында мәгълүмат аз бирелүенең сәбәбен исә ул болай дип ачыклый: «Ибн Фазланга болгарларның кыяфәтләре, кием-салымлары электән дә билгеле булган, чөнки төрки халыклар ул дәвердә Багдадта күп булганнар» (Фәхреддин 1915а: 225). Фәхреддин ул чорда Оренбург музеенда саклanучы мөселман хатын-кызларының киемнәре, бизәнү әсбаплары булуын, ләкин аларның да бик борынгы булмауларын, иң күбе йөз ел элеккеге чорга каравын яза.

Ризаэддин Фәхреддин кием-салым рәвешенең һәр чорда үзгәреш кичерүен белдереп моңа үрнәк буларак, үзе бәләкәй чакта туганнарыннан өлкән яшьтәге бер хатынның сандыгында үзе эшләгән калфак күрүен тасвирлый. Калфакның ак мамыктан бәйләнгән булуын, башка кигәч очындагы чугының җиргә тияр-тимәс булып торуын белдерә.

Кием модасының үзгәрүе белән бәйле буларак Шиһабетдин Мәрҗани дә үзенең *«Мөстәфад әл-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар»* исемле тарихи әсәрендә бу теманы телгә ала. Аның белдерүенчә, XVIII гасыр ахыры – XIX гасыр башында Казан мөселманнары кием-салымда руслар тәэсиренә бирелгәннәр. Мәсәлән, аларның бөрмәле кара чикмән, кара эшләпәләрен кигәннәр һәм шулай ук туйларда ирләр хатыннар бергә утыра торган булалар. Моңа Бохарада гыйлем алып кайткан дин әһелләренең чик куюы белдерелә (Мәрҗани 1900: 24–25).

Башка милләтләр киемен кию мәсьәләсе XIX гасырның икенче яртысында ук инде телгә алынуы мәгълүм. Шиһабетдин Мәрҗанидән бер мәҗлестә сәүдәгәр Ибраһим Акчурин эшләпә киюнең хәрам булуы яки булмавын сорый. Мәрҗани исә хәрам түгел, хәтта мәкруһ дип әйтергә дә урын юк дип җавап бирә[6] (Таиров 2012: 2).

[6] Эшләпәгә дин әһелләренең тискәре карашы әле 20 нче гасыр башында да дәвам иткән булса кирәк, чөнки Воробьев Н.И. үзенең хезмәтендә кайсыбер татарларның эшләпәнең алдан һәм артта читләрен кисеп киюләрен белдерә, моның сәбәбен исә халык яшен сугудан саклану өчен эшләвен белдерә . Автор Гали Рәхимнең исә моның сәбәбе дин әһелләренең басым ясавы аркасында икәнлеген дә язып үтә (Воробьев 1930: 365).

Ризаэддин Фәхреддин үзе мәдрәсәдә укыган чорда, ягъни XIX гасырның 70–80 нче елларында мәдрәсәләрдә бәхәсләрнең, низагъларның иң зурысы чалбар тирәсендә булуын аңлата[7]. Бу чордан башлап чалбар киюче, аның балагын тышка салындырып йөрүчеләрдән берсе мәгърифәтче Каюм Насыйри булуын да әйтеп китү кирәк (Насыйри 2017: 163). Бәхәс башта чалбар киюнең дини яктан тыелган яки рөхсәт ителгән булуы белән бәйле була. Соңрак исә бер төркем дин әһелләре чалбар киюне катгый рәвештә хәрам дисә, икенче төркем исә чалбар балагы читек яки оек балтыры эченә кыстырылса рөхсәт ителә дип дәгъва кылалар[8]. Әлеге мәсьәләдә Ризаэддин Фәхреддин шуңа игътибар итә, дин әһелләре чалбар киюне эшчеләргә рөхсәт итәләр, ләкин үзләренә киюне хәрам дип белдерәләр. Һәм ул шулай аңлата: әгәр бу хәрам икән, искәрмәсез, бөтен кешегә дә хәрам булырга тиеш (Фәхреддин 1915а: 226). Бу уңайдан Фәхреддин Уфа шәһәрендә казый булып торган вакытта үзе белән булган бер кызыклы вакыйганы да аңлатып уза. Ул Дини идарәгә казый булып килгән берәүнең кыска кием, ботинка киеп йөрүенә һәм моңа халыкның ияләшеп бетүеннән соң, аның эшләпә кия башлавы хакында бәян итә. Шулай бервакыт урамда барган вакытта Богырыслан өязе ахуны Габбас хәзрәт очрагач, Фәхреддин аны яңа казый белән таныштыра. Шунда Габбас хәзрәт: «Һай, оятлы булдым бит! Мин аны әрмән дип торам» дип җавап бирүен аңлата (Фәхреддин 1915а: 226).

1915 елда *«әд-Дин вә әл-Әдәп»* журналында милли һәм дини кием мәсьәләсе турында имзасыз бер мәкалә басыла. Аның авторы һәрхәлдә Галимҗан Баруди булырга тиеш. Бу язмада халыкның Аурупа киеменә, гореф-гадәтләренә, модасына ияреп үз йолаларын, киемнәрен югалта баруларына аның борчылуы белдерелә. Мәкаләдә автор милли бер гадәт булу белән бергә, мөселманлыкның бер ачык күрсәткече дә булып торган кәләпүш киючеләрнең дә сирәгәя баруына кайгыруын күрсәтә (Тәъәссүфле хәлләремез 1915: 207). Аның бу язмасында кәләпүшне мөселманлыкның бер билгесе, күрсәткече буларак кабул итүен аңларга мөмкин. Шулай ук 1909 елда Габдулла Нәдимнең Казанда Харитонов матба-

---

[7] Ул чорга кадәр халык арасында күпчелек киң төпле, төрле материалдан гади генә тегелгән ыштан кулланылган. Н.И. Воробьевның белдерүенчә, ул ыштаннар ирләр өчен дә, хатыннар өчен дә бер формада тегелгән.

[8] Ризаэддин Фәхреддин бу язмасында *«Аң»* журналында 1915 ел, 5 нче санда басылган *«Чалбар»* хикәясен искә ала. Хәзерге чор кешеләренә әкият кебек тоелса да, үзе шәкерт булган елларда мондый очракларның күп булуын белдерә. Г. Газиз тарафыннан язылган кыска хикәядә чалбарга каршы дошман булган Вәлиулла мулла юлда үзенең шәкерте Сәетгәрәйне чалбар кигән килеш күреп ала. Ул шәкертен ирексезләп чалбарын салырга мәҗбүр итә. Баксаң, Сәетгәрәй чалбары булмагач, җиләненең җиңнәрен аягына киеп, аны биленә бәйләп, чалбары булуы белән мактанырга дип чыккан була.

гасында басылган *«Өч мәсьәлә»*[9] исемле китабында да мөселманнарның кием-салымнары турында тәнкыйди мәгълүмат бирелә.[10]

## **‘مَنْ تَشَبَّه بِقَوْمٍ فَهُوَ مِنْهُمْ’ *“Мән тәшәббәһә бикаумин фәһүвә минһүм”* (“Кем бер кавемгә охшарга тырышса, алардан булыр”) хәдисе**

Озак вакытлар буе дин әһелләре, галимнәр тарафыннан башка милләтләргә охшауны тыю өчен кулланылган *“Мән тәшәббәһә бикаумин фәһүвә минһүм”* хәдисе белән бәйле бәхәсләр әле бүгенге көндә дә дәвам итә (Tokpınar 2005: 85–109). Әлеге хәдискә шәрех язучылар башка милләтләргә охшауны төрлечә тасвирлаганнар. Кайберәүләре тышкы кыяфәт ягыннан охшау[11] белән бергә уй, фикер йөртүдә охшауны, кайберәүләре исә башка диннәрнең символларын үзләренә алуны моңа керткәннәр (Yüksel Uysal 2016: 301). Бу хәдис татар матбугатында дин әһелләре тарафыннан да байтак искә алына. Мисал өчен, Рамил хәзрәт Юнысов белән әңгәмәдә әлеге хәдис Яңа ел бәйрәм итү белән бәйле буларак кулланыла (Басыйрова 2018).

Әбү Давыд җыентыгында китерелгән әлеге хәдис хакында Ризаэддин Фәхреддин аны кайсыбер хәдис галимнәре зәгыйфь хәдис буларак кабул итүләре турында яза[12].

Ризаэддин Фәхреддин ислам дине тарафыннан яңа бер киенү рәвеше, бер форма китерелмәвен аңлата. Киемнең гаурәтне каплаган булуы, ирләр өчен ефәктән булмавы, ирләрнең хатын-кызлар киеме, хатын-кызларның ирләр киемен кимәскә тиешлеге, шулай ук кыргый зәгъфранга буялган киемнең тыелган булуыннан башка, кием-салымда кешенең ирекле булуын белдерә. Әгәр исламият тарафыннан берәр форма билгеләнгән булса, ул иң беренче чиратта хәзрәти пәйгамбәр һәм сәхабәләр дәверендә тәгаенләгән булырга тиешлеген искәртә. Монда бары тик хаҗ вакытында киелгән ихрам гына искәрмә булып тора. Ләкин бу мәсьәлә хакында

[9] Бу рисалә мәшһүр кадимче Ишмөхәммәт ишан тарафыннан да тәнкыйть ителә. Карагыз: (Ибн Динмөхәммәт 1911: 189).

[10] *«Өч мәсьәлә»* әсәре Трансвааль мөселманнары тарафыннан Мисыр галимнәренә бирелгән өч сораудан тора. Бу сорауларга ул вакытта Мисыр мөфтие булган танылган галим Мөхәммәт Габдүһ кыска рәвештә җавап бирә. Бирелгән сорауларның әһәмиятле һәм Россия мөселманнары өчен дә кирәкле булуына басым ясаган Габдулла Нәдим әлеге фәтваларны тулыландырып, фикыһ китапларыннан өстәмәләр кертеп, киңәетеп нәшер итә. Бу өч сорау түбәндәгеләр: 1) Мөселманнарга Аурупа халкы киемен кию рөхсәт ителәме? 2) Христианнар суйган итне мөселманнарга ашау дөресме? 3) Бер мәзһәбтәге кешенең икенче мәзһәбтә булган кешегә оеп намаз укуы дөресме?

[11] Әлеге хәдис белән бәйле буларак *«Өч мәсьәлә»* рисаләсендә бу хәдиснең кием-салым белән бәйле булмавы белдерелә (Нәдим 1909: 7–8).

[12] Бу хәдиснең башка риваятьләре һәм аның зәгыйфь яки ышанычлы хәдис булуы хакында карагыз: (Tokpınar 2005: 85–109).

Коръәни Кәримдә мөселманнар өчен махсус кием белән бәйле һичбер аять булмавы белдерелә.

Мөселманнар арасында дини кием буларак танылган чалма хакында Ризаэддин Фәхреддин аның исламга кадәр үк яһүдиләр һәм һинд мәҗүсиләре тарафыннан да киелүен искәртә. Гарәпләр арасында исә чалма аз таралган булуын язып үтә.

Ризаэддин Фәхреддин кием мәсьәләсендә үзенең *«Җәвамигел-Кәлим Шәрехе»* исемле әсәрендә илле җиденче хәдискә шәрех язганда югарыдагы мәсьәләгә кагылып уза. Ул болай ди:

> «Бездә мөселманлык үлчәве кием белән булып, үзләренә мәгълүм булган формаларда йөрүчеләрне мөселман, чалма белән чапан яки җөббә кигәннәрне галим һәм фазыйл саныйлар. “Мөселман кем?” соравына каршы Рәсүлуллаһ тарафыннан: “Өстендә чапан яки җөббә һәм башында чалма булыр” рәвешендә җавап биргән бер генә хәдис китабын да күргәнебез юк. Бу хәдистә пәйгамбәребез с.г.в. “Мөселман кем?” сөаленә: “Кешеләр үзләре һәм маллары хакында аңардан имин булырлар” дип җавап бирә» (Фәхреддин 1916: 82).

128 нче хәдис аңлатмасында Фәхреддин өстенлекләрен күрсәтү өчен тәкәбберләнеп изарларын[13] җирдән сөйрәлерлек озын киючеләр турында аңлатканда болай дип яза:

> «Гарәпләр изарларын тәкәбберлек белән җирдән сөйрәлерлек итеп йөргәннәр. Рәсүлуллаһ исә моны тыйган. Ләкин монда төп максат изар түгел, ә тәкәбберлек булып тора. Шуңа күрә тәкәбберлек булмаганда изарны өстерәп йөрү, яки тәкәбберләнүчеләргә махсус формалар, хәтта кыска киемнәр кию, кәләпүшләрне, бүрекләрне кыңгыр салып йөрү дә изар кебек үк тыелган булырга мөмкин» (Фәхреддин 1916: 198).

Мөселманнарның башка кешеләрнең тышкы кыяфәтләренә, киемнәренә артык игътибар итүләре турында бер мисал китереп, Габдулла Нәдим Җамалетдин Әфганинең Петербургта татар муллалары белән очрашуын искә ала. Әфгани белән күрешер өчен махсус Петербургка килгән ике имам үз төбәкләрендәге мөселманнарның кыска кием, эшләпә киюләрен сөйлиләр һәм моны *“Кем бер кавемгә охшаса”* хәдисенә нигезләп, бу хакта Әфганинең фикерен сорыйлар. Шул кадәрле ерак арадан, шундый бер кирәксез сорау бирер өчен килүләренә гаҗәпкә калган Әфгани аларга: «Пәйгамбәребез тегүче түгел иде. Тегүчелек гыйлемен өйрәтергә дә килмәде, ул кешеләргә ике дөнья бәхетен бирәчәк дин гыйлемен өйрәтергә килде» дип җавап бирә (Нәдим 1909: 11).

Ризаэддин Фәхреддин әлеге хәдиснең башка милләтләрнең киемнәрен киюдән тыю өчен кулланылуының ялгыш булуын белдерә. Чөнки хәзрәти пәйгамбәр башка милләтләрнең киемнәрен кию, хәтта шул киемнәр белән

---

[13] Гарәпләрдә гәүдәнең билдән түбән өлешен каплау өчен кулланылган кием төре.

намаз укуы да риваять ителгәнен әйтә. Икенче яктан караганда, әгәр бу хәдис кисәтү яки чит милләтләрнең киемнәрен киюдән тыю өчен сөйләнгән булса иде, ирләргә ефәк кием, алтын йөзек тагуны тыйган кебек, ачык рәвештә хәдисләрдә белдерелгән булыр иде ди. Шулай ук, әгәр бу башка кавемнәргә охшауны тыю булса иде, ашаган вакытта чәнечке-пычак куллану, өстәл артында ашау, газета-журнал чыгару, Аурупадагы кебек сәүдә оешмалары төзү һәм башкалар да шулай ук тыелган булыр иде.

Фәхреддин бу хәдистәге **تَشَبَّه** «тәшәббәһә» фигыле охшау дигән сүз, түгел, ә охшарга тырышу дип аңлата, шуңа күрә берәр файда өчен, охшау максаты булмаган килеш киемне кигән очракта әлеге хәдискә нигезләнмәскә кирәк дип белдерә. Моның белән бергә ул, башка дин тотучыларның ачык символларын, аларның дин әһелләре тарафыннан үзләрен бүтәннәрдән аеру өчен кигән киемнәрен кулланырга ярамавын искәртә (Фәхреддин 1915б: 290). Ләкин бу очракта да моңа дәлил буларак әлеге хәдисне куллану мөмкин булмавын белдерә.

**فَهُوَ مِنْهُمْ** «Фәһүвә минһүм» (ул алардандыр) гыйбарәсен Ризаэддин Фәхреддин хәрам, мәкруһ булуы яки бу кешенең диннән чыгуын аңлатмавын яза. Бу хәдискә шәрех язучылар аны «Изгеләргә охшаучылар хөрмәт күрерләр. Бозыкларга охшаучылар хөрмәт күрмәсләр» дип халык арасында кулланылган мәгънәгә һич туры килмәгән рәвештә аңлатма бирәләр дип шәрехли (Фәхреддин 1915б: 290). Ягъни хәдистә «Кем бер кавемгә охшарга тырышса, шулардандыр» дигән вакытта, ул дин кешесе була, ягъни кяфер була дигән сүз түгел. Ә бары тик аларга охшавы сәбәпле хөрмәт күрмәс дигәнне аңлата дип әйтә.

***Дин әһелләре өчен махсус кием мәсьәләсе.*** Ризаэддин Фәхреддин дин әһелләре, галимнәре өчен махсус кием, форма кирәк булу яки булмавы турында да үз фикерен белдерә. Башка дин әһелләренең гомуми халыктан аерылып тору өчен махсус киемнәр киюен, мөселманнарда Әбү Йосыфның[14] үз вакытында галимнәр белән гади халыкны аеру өчен махсус бер форма кертүен яза. Үзе исә ислам галимнәре өчен махсус бер форманың кирәк булуы яки булмавы дәвергә, климат шартларына, дәүләтләрнең ихтыяҗына күрә хәл ителергә тиешле бер мәсьәлә булуын, шуңа күрә, катгый рәвештә кирәк яки һич кирәк түгел дип әйтергә мөмкин булмавын белдерә.

Фәхреддиннең фикеренчә, ислам дине кешеләр арасында тигезлек принципына нигезләнгән, шуңа күрә ул махсус форма булу тарафдары түгел. Әгәр берәр төрле аермачылык, өстенлек булса, бу киемдә түгел, ә

[14] Әбү Йосыф Якуб ибн Ибраһим (731, Куфә – 798, Багъдад), Әбү Хәнифәнең шәкерте. Һади (785–786) һәм Һарун әр-Рәшид (786–809) хәлифәләр вакытында казый вазыйфасын үти. Хәлифәлек тарихы өчен кыйммәтле чыганак булып торган Китаб әл-Хараҗ китабының авторы. Карагыз: (Абу Йусуф Йа'куб б. Ибрахим ал-Куфи 2001: 415).

мәгънәви яктан булырга тиеш. Голәма башкалардан күркәм әхлак, гыйффәт, күңел пакълеге белән аерылып торырга, өстен булырга тиеш ди. Ул үз сүзләренә дәлил буларак *Коръәни Кәримнән* ‘وَلِبَاسُ التَّقْوٰى ذٰلِكَ خَيْرٌ’[15] аятен китерә (Фәхреддин 1915б: 291). Ләкин моның белән бергә, Җәвамигел-Кәлим шәрехе исемле хезмәтендә зарурәт булмаган вакытта мөфти, казый, имам, мөәзин, мөдәррис һәм мөгаллимнәрнең халык ярата торган рәвештә киенергә, бигрәк тә хәдис, тәфсир, сира һәм фикыһ фәннәрен укытучыларга Пушкин, Лермонтовларга охшау максаты белән яланбаш, пумала баш булып йөрмәскә тиешләр дип белдерә. Шулай ук мәдрәсә шәкертләренең урамда халык каршында гармун тартып, скрипка, балалайка күтәреп йөрүләре дә шарт түгел. Әгәр чалмадан йөрү уңайсыз булса, бүрек һәм җөббә белән йөрү бер дә уңайсыз булмаса кирәк дип әйтә (Фәхреддин 1916: 470). Указлы бер имамның яланбаш, биленә билбау буган килеш бер яшь егет белән кызга никах укуын ишеткәч үзенең чиксез кайгыруын белдерә. Бу хакта ул «Шул вакытта гына булса да башына чалма, өстенә берәр озын кием кигән булса, кайсы җиренә кимчелек килгән булыр иде?» дип борчылуын аңлата.

Димәк, Ризаэддин Фәхреддин ислам дине тәгълиматы күзлегеннән чыгып караганда дин әһелләре өчен махсус бер форма булмавын искәртә. Ләкин дин әһелләренең, дини уку йортларында укытучыларының халык тарафыннан сөелгән, аларга килешердәй кием-салым киюләренең хәерлерәк булуын сөйли.

***Зәвык, икътисадый һәм сәламәтлек ягыннан кием-салым.*** Ризаэддин Фәхреддин киемнең кешенең эчке дөньясы белән бәйләнеше булуын, зәвык ягыннан караганда күңеленә хуш килә торган, җанына тынычлык бирә торган булырга тиешлеген белдерә. Ул үз киемнәрен яратып киючеләрнең холыклары яхшырак һәм аларның сабыррак булуын, андый кешеләр белән сөйләшү дә рәхәт булуын яза. Үз киемнәрен яратмаучыларның исә киресенчә, табигате бозыла, алар ачулы, кәефсез булалар дип аңлата.

Медицина күзлегеннән караганда, кием-салым кешене суыктан һәм эсседән сакларга, тәнне авырттырмаслык, кан әйләнешенә зарар китермәслек булырга тиеш дип ассызыклый Фәхреддин. Һәм киемне тектергән, сатып алган вакытта бу факторларга игътибар итәргә кирәк ди. Фәхреддин ул чорда татарлар арасындагы бу мәсьәләгә нинди караш булуын болай аңлатырга тырыша:

> «Безнең үз арабызда докторлар булмаганлыктан, булганнары да Аурупа модасы белән киенеп йөргәнлектән, безнең киемнәребез бүгенгә кадәр медицина фәне тарафыннан өйрәнелмәгән, сәламәтлек саклау кагыйдәләренә туры килүләре яки килмәүләре турында табибларның фикерләре соралмаган. Бәлки безнең бик файдалы киемнәребез, үзебез дә белмәгән сәбәпләр аркасында башка берәр

[15] *Әграф* сүрәсе, 26 нчы аять ‘Тәкъва киеме... ул исә тагын да хәерлерәктер’.

зарарлы формага алмашынып бара торгандыр. Яки киресенчә, бер файдалы формага алышынырга тиешле кием әле һаман өстебездәдер» (Фәхреддин 1915б: 291).

Ул шулай ук үзенең сырган бәрхет кәләпүш һәм каракүл бүрек яратып киюен, ләкин гомер буе баш авыртуы белән җәфалануын, моның сәбәбе буларак яшь вакыттан ук кышын да, җәен дә шул бүрек белән йөрүдән күрүен әйтеп китә.

Икътисадый җәһәттән Фәхреддин киемнән күреләчәк файда аңа тотылган чыгым белән пропорциональ булырга тиеш дип белдерә. Ягъни кием-салымда артык исраф кылу да дөрес булмавын искәртә. Әгәр мөселманнар үзләренең борынгы киемнәрен саклап калырга телиләр икән, иң беренче чиратта алар киемнәрен икътисадый кагыйдәләргә нигезләнеп җитештерергә тиешләр. Ул моңа мисал итеп бер сәүдәгәрнең сүзләрен китерә. Мөселманнар тарафыннан яратып киелгән каракүл бүрек уртача 15 сум тирәсе булып, Оренбург климатында ул ике ел эчендә туза. Ә фуражка, эшләпәләр 4–5 сум булып, 3–4 ел буе киярга җитә. Шулай итеп татар каракүл бүреге бу конкуренциягә чыдый алмый, гади халык теләр-теләмәс чыдамлырак баш киемен сайларга мәҗбүр була. Шуңа күрә мөселманнарга каракүл бүрек бәясен төшерергә, яки аны чыдамлырак башка төр материалдан эшләргә тиешләр дип яза.

Бу мәкаләдә Фәхреддин казакиларның кыскаруы белән бәйле мәгълүмат та биреп китә. Аның белдерүенчә, тубыкка кадәр булган казакилар Уфада 1904 елда кыскара, яңа мода керә башлый. Моны башлаучылар мөселман кибетләрендә приказчик булып эшләүчеләр була. 1915 елда инде озын казаки кию көлке булып саналыр хәлгә кала (Фәхреддин 1915а: 227). Ягъни ун ел кебек кыска бер вакыт эчендә казаки зур үзгәреш кичерә, тубыктан булган казаки тездән кала. Моның сәбәбе исә халык арасында штан урынына чалбар кию модасы тарала башлавы белән була.

***Милли кием мәсьәләсе.*** Милли кием мәсьәләсенә Фәхреддин җитди карый. Ул кием-салым милли булырга тиеш, бу исә үз чиратында шул милләт әгъзаларының үзара дус-тату торуларына, бер-берләренә ярдәм итүләренә сәбәп була дип белдерә.

Ризаэддин Фәхреддин мәкаләсендә Ибн Халдунның[16] түбәндәге сүзләрен китерә: «Җиңелгән, гаҗиз, гыйлемсез һәм мәгърифәтсез халыклар кием-салымда, көнкүрештә, җиһаз һәм әсбапларда үзләрен җиңүчеләргә, көчлерәк, гыйлемлерәк халыкларга ияреpгә табигать тарафыннан мәҗбүрләрдер» (Фәхреддин 1915а: 227). Ибн Халдунның әсәрендә Андалусия мөселманнарының гореф-гадәт, кием-салым, яшәү рәвеше буларак Испания христианнарына иярүләрен мисал буларак күрсәтелә һәм

[16] Ибн Халдун (1332–1406) – тулы исеме Әбү Зәед Габдеррахман ибн Мөхәммәд әл-Хәдрәми, танылган философ, тарихчы, социология фәненә нигез салучыларның берсе.

Ибн Халдунның моның тиздән алар җиренә башкалар хуҗа булачагына ишарәт итүен сөйләгәнен яза. Фәхреддин исә моңа үрнәк итеп русларны һәм Русия мөселманнарын китерә. Русларның элек Алтын Урда дәүләтеннән бик күп нәрсәләрне үзләренә өлге итеп алуларын, хәтта рус хатыннары кия торган сарафанның да Дәште Кыпчак төркиләреннән алынган булуын ишеткәнлеген белдерә. Соңрак исә русларның Аурупа халкыннан күп нәрсәләр алуларын искәртә. Русия мөселманнарына килгәндә, Ибн Халдун кагыйдәсенә күрә, алар иртәме-соңмы барыбер кием-салымда, көнкүрештә, өй җиһазы һәм башка нәрсәләрдә үзләреннән өстен булган русларга иярүләре турында шөбһә юк иде дип яза. Ләкин моны ашыктыручы бер сәбәп булуын, егерме биш ел алданрак килүенә аның тәэсирле булуын, әлеге сәбәпнең мөселман сәүдәгәрләренең әманәткә тугры булмаулары, кибетләрендә махсус тегүчеләр булмавы, аяк киемнәрендә размер булмавы, алдашуларның күп булуы кебек сәбәпләрне санап китә. Менә шушы нәрсәләр халкыбызның милли киемнәреннән бизеп, башкалар киемен кия башлауларына сәбәп булды ди. Кием-салым кибетләрендә махсус тегүчеләр булмагач, кибетләрдә мисал өчен тунның эчлеге булып тышлыгы өчен материал булмаса, яки тышлыгы булып якасы өчен мех булмаса, яки заказ айлар буе үтәлмәсә, халыкның әзер кием саткан кибетләргә китәчәге билгеле дип әйтә һәм моңа Уфа шәһәреннән бер үрнәк китерә:

> Ул бер рус кибетендә ботинка сайлаучы башкортка «Фәлән кеше кибетеннән кәвеш алырга ярамыймы?» дип сорый. Башкорт аңа: «Алар алдыйлар, үкчәсенә ком тутырган кәвешләрен күп (кидек дип әйтеп булмый, чөнки күп кияргә мөмкин түгел) алдык инде. Руслар кыйммәткә саталар, ләкин саткан әйберләре сыйфатлы, ул акчаны бирсәң дә ярый» дип җавап бирә (Фәхреддин 1915а: 227).

Р. Фәхреддин мәкаләсендә дини уку йортларында укыган шәкертләрнең дә милли киемне ташлауларын белдереп моңа бер үрнәк китерә. Җиде ел буе Мәккә шәһәрендә танылган бер ишанда укып кайткан берәүне Уфа урамында башына фуражка, өстенә Аурупа киеме кигәнен күреп, мондый хәлне хәтта Русиядә Учительская школа укучыларында да күргәне булмавын һәм үзенең моңа бик тәэсирләнгәнен белдерә (Фәхреддин 1915б: 292).

Р. Фәхреддин үз дәверендә милләтнең үсүгә һәм мәдәният казануга мохтаҗ булуын, шуның белән бергә үз милли әсәрләрен, әдәпләрен, гореф-гадәтләрен дә сакларга тиеш булуларын күрсәтә. Бер милләтнең мәдәни, культуралы булуы аның үз гореф-гадәтләрен онытырга, ташларга тиешле булуын аңлатмый. Ул үрнәк буларак Аурупа һәм Америка халкын күрсәтә. Аларның мәдәниятлары уртак булса да, әхлаклары, гореф-гадәтләре төрле булуын искәртә. Камилләшү, алга китү башкаларның гореф-гадәтләрен алу белән түгел, бәлки үз гореф-гадәтләреңне яхшырту белән булыр. Үз мәдәниятларын үстерергә теләгән милләтләр үзләренә хас әхлакларын, кием-салымнарын һәм, гомумән, гореф-гадәтләрен сакларга тиешле. Дини

гамәлләрдә башкаларга сукырларча иярү мактаулы эш булмаган кебек, ул шулай ук дөньяви эшләрдә дә мактаулы түгел дигән карашта тора (Фәхреддин 1915б: 291–292).

Милли киемнең саклануы Ризаэддин Фәхреддингә күрә мөнбәрләрдән сөйләнгән чыгышлар, матбугатта язылган мәкаләләр белән түгел, ә сәүдәгәрләр тырышлыгы белән була, әгәр алар тырышлык күрсәтсәләр, милли киемнәр кулланылыр, тырышмасалар бары тик музейларда гына калыр дип үзенең мәкаләсенә нәтиҗә ясый.

Ризаэддин Фәхреддиннең кием-салым белән бәйле язылган мәкаләләреннән һәм хәдисләргә язган аңлатмаларыннан чыгып аның бу мәсьәләдәге фикерләре турында түбәндәге нәтиҗәне ясарга мөмкин. Ислам дине килгәннән соң хәзрәти пәйгамбәр яңа бер кием формасы китермәде, үзе яшәгән җәмгыять һәм хәтта башка дин әһелләре нинди кием кигән булсалар ул да шуларны киде. Монда искәрмә булып бары тик кайбер очраклар гына тора, мисал өчен ирләргә ефәк, кыргый зәгъфранга буялган кием һ.б. Ягъни мөселманча кием яки ислам киеме дигән бер кием формасы шәригатьтә юк. Бу һәр халыкның климат шартларына, яшәгән җирлегенә, гореф-гадәтләренә туры килә торган киемнәрдер. Киемнең ислам дине тәгълиматы буенча бер изге тарафы юк, ләкин шул ук вакытта дин әһелләре үз вазыйфаларын башкарган вакытта, дини мәрасимнәрне үтәгән вакытта ул халык арасында таралган, мисал өчен татарлар арасында чалма-чапан киюләре кирәк. Милли киемгә килгәндә, ул сакланырга тиешле, аның бер милләт әгъзалары арасында берлек, дуслык көчәюендә әһәмияте бар. Милли киемнең саклануы бары тик матбугатта язылган мәкаләләр, мөнбәрләрдән сөйләнгән нотыклар белән генә саклана алмый. Бу эштә төп вазыйфаның милли кием җитештерүче сәүдәгәрләрнең өстенә йөкләнүе турындагы караш алга сөрелә.

## ЧЫГАНАКЛАР ҺӘМ МАТЕРИАЛЛАР

Абу Йусуф Йа’куб 2001 – Абу Йусуф Йа’куб б. Ибрахим ал-Куфи. Китаб ал-Харадж / пер. с араб. и комментарии А.Э. Шмидта. Супракомментарии к переводу А.С. Боголюбова. Подготовка к изданию, вступ. статья и указатели А.А. Хисматуллина. СПб.: Центр «Петербургское востоковедение», 2001.

Ачык йөз 1910 – Ачык йөз (авторның псевдонимы) Бетсен чапан, күтәрелсен йөздән пәрдәләр. Казан: Чижова матбагасы, 1910.

Басыйрова 2018 – Басыйрова Э. Хәләл сырадан тыелырга кирәк // Акчарлак газетасы. 28 сентябрь. 2018. https://akcharlak.com/article/kh-l-l-syradan-tyelyrga-kir-k/

Ибн Динмөхәммәт 1911 – Ибн Динмөхәммәт. Исгъаф әл-мәрам ган истисфарил-әхван // Дин вә мәгыйшәт. 1911. № 12. Б. 189.

Мәрҗани 1900 – Мәрҗани Ш. Мөстәфадел-әхбар фи әхвали Казан вә Болгар. Икенче кисәк. Казан, 1900.

Насыйри 2017 – Насыйри К. Кием-салым // Шура. 2017. № 18. Б. 256.

Нәдим 1909 – Нәдим Г. Өч мәсьәлә. Казан: Харитонов матбагасы, 1909.

Рэмзи 1911 – Рэмзи М. Гафлэтмедер игъфалмедер шашкынлыкмыдыр // Дин вә мәгыйшәт. 1911. № 7. Б. 103–106.
Сахибе 1906 – Сахибе (авторның псевдонимы). Чапан илә пальто гаугасы яки иске вә яңалык. Казан: Матбага-и Кәримия, 1906.
Таҗетдинов 1910 – Таҗетдинов И. Мөрасәлә вә Мөхабәрә // Шура. 1910. № 2. Б. 62.
Тәъәссүфле хәлләремез 1915 – Тәъәссүфле хәлләремез // әд-Дин вә әл-Әдәп. 1915. № 7. Б. 207–212.
Фәхреддин 1915а – Фәхреддин Р. (журналда Р. Ф. буларак бирелгән) Киемнәр хакында // Шура. 1915. № 8. Б. 225–228.
Фәхреддин 1915б – Фәхреддин Р. (журналда Р. Ф. буларак бирелгән) Киемнәр хакында // Шура. № 10. Б. 290–292.
Фәхреддин 1916 – Фәхреддин Р. Җәвамигел-Кәлим шәрехе. Оренбург, 1916.

## ФӘННИ ӘДӘБИЯТ

Воробьев Н.И. Материальная культура казанских татар. Казань, 1930.
Таиров Н. Идел буе, Урал төбәкләрендә Ислам дине һәм татар эшмәкәрләре // Дин вә мәгыйшәт. 2012. № 25. Б. 4.
Tokpınar Mirza. Men teşebbehe bi-kavmin fe-hüve minhum' hadisi üzerine bir inceleme // Hadis Tetkikleri dergisi. III/2. 2005. Ss. 85–109.
Yüksel Uysal Şule. «Men teşebbehe bi kavmin» hadisini küresel giyim kültürü açısından okumak // Turkish Studies International Periodical for the Languages, Literature and History of Turkish or Turkic Volume 11/7 Spring. 2016. Ss. 294–314.

**Автор турында белешмә:** Мифтахов Ильяс Госман улы – Әнкара Университетының ислам тарихы бүлеге магистры (Эмниет мәхәлләсе, Дөгел урамы 6А, 06560 Йенимәхәллә, Әнкара, Төркия), dajbog12@gmail.com

*Редакциягә керде 22.07.2020* *Басылуга кабул ителде 02.11.2020*
*Басылды 25.11.2020*

## RIZAEDDIN FAKHREDDIN'S ARTICLES IN *"SHURA"* MAGAZINE REGARDING RELIGIOUS AND NATIONAL CLOTHING

***I.G. Miftakhov***

*Ankara University*
*Ankara, Turkey*
*dajbog12@gmail.com*

This paper analyzes the articles, statements of the famous scientist, theologian, writer, and journalist Rizaeddin Fakhreddin named "About Clothes". The article was published in the *"Shura"* magazine, where he worked as editor-in-chief. In his articles, Fakhreddin deeply analyzes the religious, national, economic, and medical aspects of clothing. The study examines such issues as the presence or absence of special clothing for Muslims, clothing of other nationalities and religions. Fakhreddin tries to explain that

clothing does not have a sacred connotation according to Islamic theology and notes that it only affects a person's character and behavior. Fakhreddin's articles say that there is no special attire prescribed by Islam for the clergy and that each nation has its clothing in accordance with climatic conditions and customs. Rizaeddin Fakhreddin emphasizes that theologians (*'ulama'*) and clergy should be distinguished from everyone else by their excellent knowledge and high ethics, and not by their outer dress. Nevertheless, the clergy should wear clothes that people consider religious; for example, among the Tatars, such clothes are Turban and Chapan. He had a strong position concerning the preservation of national clothing, emphasizing its need for a nation and noticing its relevance for all times. In his opinion, it is not possible to preserve the national costume through sermons from the pulpits of mosques, articles in newspapers and magazines. In this matter, the primary responsibility in preserving national dresses lies on those people who produce and distribute national clothes. These articles by Rizaeddin Fakhreddin on the preservation of national clothing are an essential source for studying the Tatars' daily life and the attitude of the Jadids regarding clothing at the beginning of the XX century.

**Keywords:** Rizaeddin Fakhreddin, Tatars, *Shura* magazine, National and religious clothing, beginning of XX century, Islam

**For citation:** Miftakhov I.G. Rizaeddin Fäkhreddinneñ *«Shura»* zhurnalyndagy dini häm milli kiem belän bäyle mäkaläläre [Rizaeddin Fakhreddin's Articles in *"Shura"* Magazine regarding to Religious and National Clothing]. *Istoricheskaya etnologiya*, 2020, vol. 5, no. 2, pp. 254–268. https://doi.org/10.22378/he.2020-5-2.254-268

REFERENCES

Vorobyev N.İ. *Materyyal'naya Kul'tura Kazanskykh Tatar* [Material Culture of the Kazan Tatars]. Kazan, 1930. (In Russian)

Tairov N. İdel Buyı, Ural Töbäklärendä İslam Dine häm Tatar Eşmäkärläre [Islam Religion and Tatar Businessmen in the İdil-Ural Region]. *Din ve mägıyşät*, 2012, no. 25, pp. 2. (In Tatar)

Tokpınar Mirza «Men Teşebbehe bi-Kavmin fe-hüve Minhum» Hadisi Üzerine Bir İnceleme [A Discussion about «Men teshebbehe bi-kavmin fe-huve minhum»]. *Hadith Studies*, 2005, III/2, pp. 85–109. (In Turkish)

Yüksel Uysal Şule «Men teşebbehe bi kavmin» Hadisini Küresel Giyim Kültürü Açısından Okumak [«Men teshebbehe bi kavmin» Reading the Hadiths from the Perspective of Global Clothing Culture]. *Turkish Studies International Periodical for the Languages, Literature and History of Turkish or Turkic.* Vol. 11/7. Spring, 2016, pp. 294–314 (In Turkish).

**About the author:** İlias Miftakhov is a Master's degree student of History of Islam at Ankara University (Emniyet mahallah, 6A Dögol Cd., 06560 Yenimahalle, Ankara, Turkey); dajbog12@gmail.com

*Received July 22, 2020* *Accepted for publication November 02, 2020*
*Published November 25, 2020*

# СТАТЬИ РИЗАЭДДИНА ФАХРЕДДИНА О РЕЛИГИОЗНОЙ И НАЦИОНАЛЬНОЙ ОДЕЖДЕ В ЖУРНАЛЕ *«ШУРА»*

***И.Г. Мифтахов***

*Анкарский университет*
*Анкара, Турция*
*dajbog12@gmail.com*

В данной работе анализируются статьи и высказывания известного ученого, богослова, писателя и журналиста Ризаэддина Фахреддина, опубликованные в рубрике «Об одежде» журнала *«Шура»*, где он работал главным редактором. В своих статьях Фахреддин проводит глубокий анализ религиозных, национальных, экономических и медицинских аспектов в одежде. В исследуемой работе рассматриваются такие вопросы, как наличие или отсутствие специальной одежды для мусульман и ношение одежды, традиционной для других национальностей и вероисповеданий. Фахреддин пытается объяснить, что одежда не сакральна с точки зрения ислама, что она всего лишь оказывает влияние на характер и поведение человека. Автор пишет о том, что не существует специального одеяния, предписываемого исламом для священнослужителей, и что у каждой нации есть своя одежда, соответствующая климатическим условиям и обычаям. Акцент делается на том, что ученым (*улемы*) и духовенству, прежде всего, следует отличаться от остальных людей хорошими знаниями и высокой нравственностью, а не внешним одеянием. Вместе с тем представителям духовенства желательно носить ту одежду, которая считается у их народа религиозной; у татар, например, отличительной особенностью одежды религиозных деятелей являются *чалма* и *чапан*. Татарский деятель занимает твердую позицию по отношению к сохранению национальной одежды, подчеркивает ее необходимость и актуальность во все времена. По его мнению, сохранить национальный костюм невозможно проповедями с кафедр мечетей, статьями в газетах и журналах. В этом вопросе основная ответственность лежит на тех, кто производит национальную одежду, и на тех, кто ее распространяет. Статьи Фахреддина в журнале *«Шура»*, посвященные проблеме сохранения национальной одежды, являются важным источником при изучении повседневной жизни татар и передают отношение джадидов к одежде в начале XX века.

**Ключевые слова:** Ризаэддин Фахреддин, татары, журнал *«Шура»*, религиозная форма, национальная одежда, начало XX века, ислам, джадидизм

**Для цитирования:** Мифтахов И.Г. Ризаэддин Фәхреддиннең *«Шура»* журналындагы дини һәм милли кием белән бәйле мәкаләләре // Историческая этнология. 2020. Т. 5, № 2. С. 254–268. https://doi.org/10.22378/he.2020-5-2.254-268

**Сведения об авторе:** Мифтахов Ильяс Гусманович – магистр отделения истории ислама Анкарского университета (Махалле Эмният, ул. Догел 6А., 06560 Йенимахалле, Анкара, Турция), dajbog12@gmail.com

*Поступила 22.07.2020* *Принята к публикации 02.11.2020*
*Опубликована 25.11.2020*